Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
карары

2 июнь 2020 ел № 702

Транспорт чаралары хәрәкәтен
вакытлыча ябу турында

Шәһәр эстакадасында капиталь ремонт ясалуга бәйле рәвештә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 04 июненнән башлап эшләр тәмамланганчы Белоглазов урамыннан Нефтьчеләр урамына кадәр участокта транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча ябарга.

2. «Автомобиль юллары шәһәр идарәсе» муниципаль унитар предприятиесенә (Хаҗипов Р.М.) подряд оешмасын әлеге участокта «Торак сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалыгы департаменты» муниципаль автоном учреждениесе (Сөләйманов З.А.) белән транспорт чаралары хәрәкәтенең ябылуын килештерергә, тиешле юл билгеләрен урнаштырырга һәм су белән тәэмин итү блоклары белән эшләр башкару участогын киртәләргә.

3. Эш участогын ябу чорында шәһәр эстакадаларын әйләнеп үтүне Радищев, Бигәш, Макаренко урамнары буйлап башкарырга.

4. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга

5. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлегенә (Зарипова Л.Н.) халыкка транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча ябу турында хәбәр итәргә.

6. Әлеге карар 2020 елның 04 июненнән үз көченә керә

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов